
**Бергәләп өйрәник**



**Җиңү көне**

**Әти-әниләр өчен ярдәмлек**

**(5-6 яшь)**

**Мәкальләр, әйтемнәр**:

а) Ватанга хезмәт – үзеңә хезмәт.
б) Ил тыныч булса – без дә тыныч.
в) Илдә яшисең икән – илеңә хезмәт ит.
г) Батыр егет – ил күрке.
***

**Шигырь уку: Э.Шәрифуллина. «Минем бабай».**

Минем бабам – капитан,
Сугышта булып кайткан.
Күкрәк тулы орденнар,
Медальләр алып кайткан.

Безнең илдә һәр бала
Уйнап-көлеп йөрсен дип,
Хәвеф-хәтәр күрмәсен,
Тыныч булып үссен дип,
Көрәшкән чакта бабам,
Әни
Нәкъ минем яшьтә булган,
Рәсем ясап, хат язып,
Бабама салып торган.

Бик күп сугышкан бабам,
Дошманны җиңеп кайткан.
Үзе белән ул безгә
Тынычлык алып кайткан!

**Балаларга сораулар:**

- Бабай сугышта кем булган?
- Орден, медальләрне бабайга ни өчен биргәннәр?
- Бабай нинди уйлар белән сугышка кергән?
- Җиңү безгә нәрсә китерде?

***

Солдатлар.
Бабай да солдат булган,
Әти дә солдат булган,
Зур абый да, солдат булып,
Ил чикләрендә торган...
Кече абый солдат булып
Китте быел яз гына.
Мин үзем дә солдат булам,
Үсим әле аз гына.
Клара Булатова

**Үстерешле диалог**

- Ватанны кемнәр саклый?
- Алар Ватанны кемнән саклыйлар?
- Хәрбиләрнең нинди төрләрен беләсез?
- Сезнең әтиләрегез, абыйларыгыз армиядә кем булып хезмәт иткәннәр?
- Малайлар, зур булгач, кайда хезмәт итәсегез килә? - Сез ничек уйлыйсыз, хәрбиләр нинди булалар?

**«Әйе – юк» уены**

- Самолётны кем йөртә, матросмы?
- Самолётны кем йөртә, очучымы?
- Корабльне кем йөртә, очучымы?
- Корабльне кем йөртә, матросмы?
- Танкны кем йөртә, матросмы?
- Танкны кем йөртә, танкистмы?

- Чикләрне кем саклый, матросмы?